ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

« 22 » сентябрь 2017 ел **№13**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Наласа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым җыюга карата сез килешәсезме, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан тыш, алар өчен түләүләр күләме 150 сум тәшкил итә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү урыннарын тоту | Наласа авылы зиратының коймасын ремонтлау һәм аның янындагы территорияне төзекләндерү |
| 2 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Су җыю колонкаларын ремонтлау, агач конструкцияләрне Наласа авылы, Урта Бирәзә авылы профнастиленә алыштыру |
| 3 | Җирлек территориясен | Урта Бирәзә авылы торак пунктында |

| | | |
|---|---|---|
| | тәзекләндерүне оештыру | урамнарны яктыртуны ремонтлау. |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов ур., 64 йорт, ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы: И.Р.Шакирова